# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге составына керүче Отарка торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында

№2 18 октябрь 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең Отарка торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Отарка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Отарка торак пунктында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү)

-Отарка торак пунктында юлларны кардан чистарту;

-Отарка торак пунктында чишмәне төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

3. Әлеге карарны Отарка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.И.Фазылов